КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 28 гыйнвар г.Казань № 51

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга «Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 11 сыйныфларында белем алучыларны акчалата бүләкләү турында» 2025 ел, 12 май, 311 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга «Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 11 сыйныфларында белем алучыларны акчалата бүләкләү турында» 2025 ел, 12 май, 311 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 26 сентябрь, 764 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2025 елга» сүзләрен «2026 елга» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта:

икенче абзацта «2025 елга» сүзләрен «2026 елга» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «2025 елга» сүзләрен «2026 елга» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «2025 елга» сүзләрен «2026 елга» сүзләренә алмаштырырга, «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 87-ТРЗ номерлы» сүзләрен «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2025 елның 29 ноябрендәге 81-ТРЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2025 елга «Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 11 сыйныфларында белем алучыларга акчалата бүләкләү бирү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

исемендә «2025 елга» сүзләрен «2026 елга» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктта:

өченче абзацта «5 – 6 сыйныфларда белем алучылар – 1 урыннан 78 урынга кадәр» сүзләрен «5 – 6 сыйныфларда белем алучылар – 1 урыннан 60 урынга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «7 – 8 сыйныфларда белем алучылар – 1 урыннан 80 урынга кадәр» сүзләрен «7 сыйныфларда белем алучылар – 1 урыннан 30 урынга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «9 – 11 сыйныфларда белем алучылар – 1 урыннан 42 урынга кадәр» сүзләрен «8 – 11 сыйныфларда белем алучылар – 1 урыннан 110 урынга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2025 елга «Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 11 сыйныфларында белем алучыларның акчалата бүләкләү алучылар санын һәм күләмен яңа редакциядә (кararга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карарның гамәле 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 12 май, 311 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 28 гыйнвар, 51 нче
карары редакциясендә)

2026 елга «Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 11 сыйныфларында белем алучыларның акчалата бүләкләү алучылар саны һәм күләме

| Т/с | Алучылар категориясе | Алучылар саны, кеше | Бер белем алучыга акчалата бүләкләү күләме, сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 6 сыйныфларында белем алучылар | 60 | 57 500 |
| 2. | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 7 сыйныфларында белем алучылар | 30 | 57 500 |
| 3. | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 8 – 11 сыйныфларында белем алучылар | 110 | 57 500 |

_______________________